**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлеге аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлегендә Яңа Нәдер авылының Урман урамындагы 9 йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлеге Яңа Нәдер авылындагы эпизоотия чыганагы чикләреннән 2 км радиустагы территориядә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 9 февралендәге ПУ-105 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 13 апрель
№ ПУ-268